# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Тәрекләр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"29" март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 29 мартында 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Тәрекләр торак пунктында гражданнар Җыенының 17.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

"2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Тәрекләр авылындагы үләннәрне чабу).

2. Ремонтлау, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (материаллар сатып алу, Тәрекләр авылындагы зират өчен койма кую (контракт буенча эш өчен түләү, смета буенча); Тәрекләр авылында территорияне чистарту; зират, үләннәрен чабу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 83 (сиксән ) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 47 (кырык җиде) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 47 (кырык җиде) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Тәрекләр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. "Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Тәрекләр торак пунктында гражданнар Җыенының 17.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү" :

"2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Төрекләр авылындагы үләннәрне чабу).

2.Ремонтлау, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (материаллар сатып алу, Төрекләр авылындагы зират өчен койма кую (контракт буенча эш өчен түләү, смета буенча); Төрекләр авылында территорияне чистарту; зират, үләннәрен чабу).

мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Төрекләр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы — Низамиев Ф.Ф.